# Әтнә районы Түбән Көек төп белем мәктәбе башлангыч профсоюз оешмасының 2019-2024 нче еллардагы эшчәнлеге буенча отчёты.

Бүгенге көндә без дөньяда һәм илебездә барган кискен социаль-икътисади, сәяси үзгәрешләр чорында яшибез. Шуңа күрә дә Профсоюзларның төп миссиясе - эшчеләрнең социаль-икътисади мәнфәгатьләрен яклау. Профсоюз мәгариф оешмаларында хезмәткәрләрнең хезмәт хокукларын яклаучы, социаль гарантияләрне үтәүне, хезмәтне саклауны контрольләүче, лаеклы хезмәт өчен тиешле шартлар тудыруны таләп итүче бердәнбер оешма булып тора. Профсоюз комитеты үзенең эшчәнлеген Россия Федерациясенең халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре профсоюзы Уставына, Россия Федерациясенең «Профессиональ союзлар, аларның хокуклары һәм эшчәнлек гарантияләре турында» гы законына, гамәлдәге законнарга нигезләнеп оештыра.

Мәктәбебездә башлангыч профсоюз оешмасы 1991 нче елда Әтнә районы оешканнан бирле үзенең эшчәнлеген башлап җибәреп, бүгенге көнгәчә мәгариф хезмәткәрләренең район профсоюз оешмасының составында уңышлы эшләп килә. Коллективыбызда эшләүче хезмәткәрләрнең барысы да башлангыч профсоюз оешмасында профсоюз члены булып теркәлгән. Бу сан коллективта 100% профсоюз членлыгын күрсәтә. Һәр профсоюз члены АИС автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәлгән, аларга электрон профсоюз билетлары тапшырылган.

Коллективтагы хезмәткәләрнең 16 сы педагоглар, 11 е - хезмәт күрсәтүче персонал. Коллективта яшьләр саны - 4 Укытучыларның уртача нагрузкасы 18 сәгатьтән күбрәк. Педагогик состав төп фәннәр белгечләре белән тәэмин ителгән.

1. **Оештыру эшләре**

Башлангыч профсоюз оешмасының профсоюз комитеты алдагы Отчет-сайлау җыелышында 7 кеше составында сайлап куелган иде. Профком профсоюз оешмасының иң актив членнарыннан тора. Эшчәнлек һәр уку елына төзелгән Еллык план нигезендә алып барыла.

Профсоюз оешмасының төп эше нигездә эшчеләрнең мәнфәгатьләрен яклаудан, коллективтагы уңай микроклиматны саклаудан, профсоюз членнарының сәламәтлекләрен кайгырту, буш вакытларын файдалы итеп оештырудан,аларны спортка ,сәламәт яшәү тормышына тартудан гыйбарәт. Ә иң беренче чиратта, оешмабызның һәр профсоюз члены үзенең проблемалары белән барырлык оешма,аңа ярдәм итәргә әзер булган кешеләр барын белүе мөһим.

Статистика саннарына мөрәҗәгать итсәк, кеше үз гомеренең өчтән бер өлешен эштә – хезмәт коллективларында уздыра икән. Шуңа да коллективны берләштерү бурычы профсоюз комитетының төп бурычларының берсе. Без барлык хезмәткәрләрне: администрацияне, педагогларны, техник персоналны һөнәри эшчәнлек белән генә түгел, уртак проектлар, шөгыльләр, спорт, ял чаралары белән дә берләштерергә тырышабыз. Бергә булганда тәҗрибә уртаклашу, фикерләшү, конкурсларга әзерләнү, авырлыкларны җиңү, туган проблемаларны чишү, шатлык һәм кайгыларны уртаклашу һәрвакыт җиңелрәк.

## 2. **Социаль партнерлык**

Коллектив договор социаль партнерлык системасында бердәнбер рәсми документ. Коллектив договор төзү мәгариф оешмасы җитәкчесе өчен дә, башлангыч профсоюз оешмасы, аерым хезмәткәр өчен дә мөһим, ул хезмәттәшлек принципларына нигезләнә. Коллектив договорның эчтәлегенә хезмәткәрләр үзләре дә тәгъдимнәр кертә ала. Шулай итеп, профсоюз членнары да идарә итүдә катнаша ала дигән сүз. Килешү гамәлдәге хезмәт законнары кысаларын киңәйтергә, хезмәтне саклау буенча чараларны өстәмә финанслауны тәэмин итәргә, хезмәткәрләрнең хезмәт һәм көнкүреш шартларын яхшыртырга, аларга матди ярдәм күрсәтергә мөмкинлек бирә. Мәгариф оешмасы җитәкчесе өчен Коллектив договор-эшнең сыйфатын үстерү һәм нәтиҗәсен арттыру, тотрыклык тудыру механизмы булып тора. Килешүдәге социаль гарантияләр, стимул бирүче өстәмә түләүләр, эш вакытыннан тыш өстәмә хезмәт өчен компенсацияләр, премияләр бирү юллары хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүгә, коллективтагы дустанә мөнәсәбәткә, якларның үзара хөрмәтенә китерә.

Бүгенге көндә без социаль партнер белән хезмәттәшлекне 2024-2026 елларга кабул ителгән Коллектив договор нигезендә оештырабыз. Март аенда Коллектив договорның проект варианты башта профком утырышында өйрәнелде, өстәмәләр кертелде. Профсоюз членнарына танышу өчен Килешүнең электрон варианты коллективыбызның уртак социаль челтәр группасына куеды. Социаль партнер белән фикер алышулар узып , профсоюз җыелышында расланды. Коллектив договор 2024 нче елның 26 нчы мартында кабул ителеп, Әтнә районының мәшгульлек үзәгендә рәсмиләштерелде, аның электрон варианты мәктәбебез сайтының Профсоюз битендә урнаштырылды. Коллектив договор төп 14 бүлектән тора. Киләчәктә мөһим үзгәрешләр булганда Коллектив договорга килешүгә кул куйган яклар ризалыгы белән өстәмәләр кертү мөмкинлеге бар.

Тагын бер әһәмиятле документ ул - оешма җитәкчесе һәм хезмәткәр арасында төзелә торган Хезмәт килешүе - ике зат арасындагы социаль-хезмәт шартларын көйләүче документ. Анда хезмәткә түләү, хезмәтне саклау, мәшгульлек, эш һәм ял вакытын билгеләү, пособиеләр һәм компенсацияләр бирү, социаль-хезмәт шартларына кагылышлы башка мәсьәләләр билгеләнә. Хезмәткәрләр һәм оешма

җитәкчеләре арасында төзелгән Хезмәт килешүләре Россия Федерациясенең Хезмәт Кодексының 10 бүлегендәге статьяларга нигезләнеп төзелгән булуы шарт. Бүгенге көндә һәр хезмәткәр белән Хезмәт килешүе тәзелгән.

## 3. Информацион эшчәнлек.

Профсоюз комитеты профсоюз әгъзаларына, шулай ук мәктәпнең бөтен җәмәгатьчелегенә мәгълүмат бирү өчен профкомның Профсоюз почмагын файдалана. Мәгълүмат стенды профсоюз члennarын профсоюз оешмасының эшчәнлеге белән таныштырып бару өчен отышлы юл. Анда планнар, профком карарлары, белдерүләр, котлаулар урнаштырыла. Хәзер без информацион технологияләр чорында яшибез. Мәгариф системасына, Профсоюзлар эшчәнлегенә кагылышлы төрле карарлар, норматив документлар белән район семинарларында даими таныштырылып барыла. Бу мәгълүматлар профсоюз членнарының шәхси почталарына җибәрелә. Заманча чаралар белән беррәттән, шәхси элемтәгә нигезләнгән мәгълүмат җиткерүнең традицион ысуллары да уңышлы файдалана.

Ел да башлангыч профсоюз оешмасы исеменә “Учительская газета”сының кушымтасы “Мой профсоюз” газетасы яздырыла. Газетада урын алган актуаль мәкаләләр, норматив документлар, башка төбәкләрнең профсоюз тормышындагы кызыклы тәҗрибәләре профсоюз членнарына вакытында җиткерелеп бара.

Шулай ук һәр профсоюз члены Гомумроссия мәгариф профсоюзының Татарстан республика оешмасы сайтына кереп, үзен кызыксындырган сорауга, үзен борчыган проблема буенча җавап таба ала.

АИС автоматлаштырылган мәгълүмат системасында башлангыч профсоюз оешмасы турында тулы мәгълүмат туплау, статистик отчетларны система аша тапшыру юлы профсоюз оешмаларының мөмкинлекләрен арттырды.

## 4. Хезмәткәрләрнең социаль-икътисади мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклау буенча чаралар

Хезмәткәрләргә каралган социаль гарантияләр закон нигезендә билгеләнгән һәм өстәмә гарантияләргә бүленә. Дәүләт тарафыннан рәсмиләштерелгән социаль гарантияләр Россия Федерациясенең Хезмәт Кодексы һәм өстәмә норматив актлар белән ныгытылса. өстәмә льгота һәм гарантияләр мәгариф оешмасы җитәкчесе һәм профсоюз комитеты арасында төзелгән Коллектив договорга нигезләнә.

Бүген мәктәпнең барлык хезмәткәрләре дә Коллектив килешүдә каралган һәм рәсмиләштерелгән социаль ташламалардан тулысынча файдаланалар.Мәсәлән, хезмәткәрләребез түбәндәге социаль сәбәпләр буенча өстәмә ял көннәре белән файдаланалар:

-"Әниләр көне" –

-Хезмәткәрнең никахы-

-Балаларның никахы-
- Якыннарның үлеме-
-Улын армиягә озату -
-Беренче сыйныф укучыларының ата-аналарына-
-Башлангыч сыйныф укучыларының ата-аналарына -
-Ата-аналары 80 яшьтән өлкәнрәк булган эшчеләргә -

Ел да хезмәткәрләргә хезмәт хакы Коллектив килешүдә билгеләнгән срокларда вакытында һәм тулы күләмдә түләнә.Хезмәт хакы һәр ярты ай саен пластик карталарга күчерелә. Хезмәт хакын түләү көннәре булып агымдагы айның 26 һәм 11 нче көннәре санала. Хезмәт хакын исәпләү буенча хезмәткәргә исәп-хисап кәгазе тапшырыла, анда: тиешле чорда аңа тиешле хезмәт хакының состав өлешләре күрсәтелә.

Оешмабызда хезмәткәрләрнең сәламәтлеген саклау мәсьәләсе дә игътибар үзәгендә тора. Администрация белән берлектә оештырылып, график нигезендә еллык медицина тикшерүләре аша оешмабызның барлык хезмәткәрләр дә уза. Медицина тикшерүенә баручы укытучыларга расписаниедагы дәрес вакытларын көйләү мөмкинлеге тудырыла.

Профсоюз членнарын ташламалы путевкалар белән тәэмин итү Профсоюзларның иң әһәмиятле һәм кирәкле проектларның берсе. Республикабызда урнашкан санаторийларга хезмәткәрләр ел дәвамында ташламалы путевкалар белән файдалана ала. Моннан тыш каникул чорларында профсоюз членнары өчен төрле туристик маршрутлар белән Сочи, Анапа шәһәрләренә ташламалы путевкалар белән барып, ял итү мөмкинлеге тудырыла. *Бу проектларда безнең оешмадан файдаланучы хезмәткәрләрләр булмау кызганыч.*

- Профсоюз членнарының балаларын сәламәтләндерү һәм ял итүне оештыру буенча аерым эш алып барыла. Инде популярлык казанган инвалид балаларга юнәлтелгән “Мать и дитя”-“Әни һәм бала “проекты буенча инвалид балага әнисе белән бергә 10 көнгә санаторийда бушлай реабилитация узарга мөмкинлек бирә.
- Авыл җирлекләрендә яшәүче һәм эшләүче педагогик хезмәткәрләргә җылыту чыгымнарын компенсацияләү льготасыннан 16 педагог һәм 6 ветеран укытучы файдалана.
- Оешмабызда зыянлы хезмәт шартларында эшләү өчен өстәмә түләү__кешегә түләнелә, ___хезмәткәр өстәмә ял көннәре белән файдалана.
- Педагогларыбыз аттестация узганда экспертизаның гадиләштерелгән формаларын куллану льготасы белән файдаланды.

нигезендә__профсоюз членына матди ярдәм күрсәтелде.

Коллективыбызның аерым билгеләп үтәргә лаеклы күрсәткече: профком исеменә профсоюз оешмасы членнарыннан үз хезмәт хокукларын бозу, вакытында хезмәт хакын бирмәү очраклары, тиешле ял көннәре бирелмәү

турында язма гаризалар һәм телдән мөрәҗәгатьләр кермәде. Бу администрациянең төп вазыйфаларын төгәл башкаруын ачык күрсәтүче мисал. Шулай ук отчет чорында оешманың Низаг комиссиясенә коллективтагы үзара конфликтлар буенча мөрәҗәгать итүчеләр булмады.

**4. Хезмәтне саклау**

Гражданнарның Россия Федерациясе Конституциясенең 37 статьясында беркетелгән төп хокук - ул һәрбер эшченең хезмәтне саклау таләпләренә җавап бирүче шартларда эшләү хокукы. Шуңа күрә дә хезмәтне саклау мәсьәләләре профсоюз оешмаларының контролендә торган төп юнәлешләренең берсе булырга тиеш. **Түбән Көек төп белем** мәктәбендә хезмәт иминлеген тәэмин итү укыту-тәрбия процессы барышында да, хезмәткәрләргә тиешле эш шартлары булдыру юнәлешендә дә, тормыш иминлеге кагыйдәләрен хезмәткәрләр һәм укучылар тарафыннан төгәл үтәлешен тәэмин ителү өстенлекле бурычларның берсе булып кала.

Оешмада һәркем иминлек һәм балаларның тормышы , сәламәтлеге өчен җавап бирә. Профком һәм администрация куркынычсызлык техникасы мәсьәләләрен хәл итүгә бергәләп тотынсалар, нәтиҗәләре дә уңай була. Иминлекне тәэмин итү беренче чиратта норматив-хокукый актларга нигезләнеп, эчке документларны тәртипкә китерүне таләп итә. Бу юнәлештә безнең оешмада администрация һәм профсоюз оешмасы арасында Хезмәтне саклау килешүе төзелгән,администрация каршында Хезмәтне саклау комиссиясе булдырылган, тиешле приказлар чыгарылган. Профсоюз оешмасыннан хезмәтне саклау буенча вәкаләтле вәкил сайлап куелган. Оешмабызда Куркынычсызлык техникасы буенча таләп ителгән журналлар булдырылган. Оешма хезмәткәрләре белән даими инструктажлар үткәрелә.

Аерым кабинетларда Куркынычсызлык техникасы буенча почмаклар булдырылган, төрле ситуацияләрдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, аерым эш төрләрен башкаргандагы инструкцияләр урын алган. Инструкцияләр мәктәп директоры тарафыннан расланган, *профком рәисе белән килешенеп имзаланган.*

Мәктәп бинасында янгын вакытында эвакуация оештыру тәртипләре ,эвакуация планнары урнаштырылган. Шулай ук террорчылык актлары шартларында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре буенча күрсәтмә материаллар урнаштырылган.

**5. Мәдәни-массакүләм һәм спорт эшченлеге.**

Профком эшчәнлегенең бер юнәлеше булып мәдәни-массакүләм эш тора, чөнки яхшы ял итә белү иҗадилыкны үстерә, тормыш тонусын күтәрүгә, җылы микроклимат булдыруга, коллективны берләштерүгә ярдәм итә. Ә иң мөһиме, коллективтагы ачылмаган талантларны күрү һәм файдалану механизмы булып тора.

Мәктәбебездә хезмәткәрләрне һөнәри һәм календарь бәйрәмнәре, юбилей даталары, никахлашу, бала тууы белән котлау чаралары яхшы традициягә әверелде.Профсоюз счетыннан профсоюз членнарына Укытучылар көне, (*Мәктәпкәчә белем бирү хезмәткәре көне, Поварлар коне,)* профсоюз членнарына Яңа ел бүләкләре, Ватанны саклаучылар көне, 8 Март бәйрәме уңаеннан бүләкләр әзерлибез. Юбилей даталарына атап хезмәткәрләргә тантаналы төстә коллектив исеменнән бүләкләр тапшырыла. Бу уңайдан без ветеран – укытучыларыбыз, хезмәткәрләребезне дә игътибарсыз калдырмыйбыз, аларны өйләренә барып котлыйбыз. Бүгенге болгавыр заманда һәр кеше дә үзенә карата игътибарга, җылы сүзгә ихлас шатлана.

2023 нче ел Россия күләмендә Укытучы һәм остаз елы буларак игълан ителүе укытучы һөнәренең абруен күтәрүгә зур этәргеч булды. Республика, район күләмендә бу уңайдан зур чаралар уздырылды. Шул исәптән безнең коллективыбыз да да андый чаралар үткәрелде.

## 6. Финанс эшчәнлеге

Башлангыч профсоюз оешмасы Әтнә территориаль профсоюз оешмасы составында керә. Профсоюз Уставы нигезендә эшкә урнашучы һәрбер хезмәткәр белән профком членнары профсоюз члены булуның өстенлекле якларын аңлатып әңгәмә үткәрәләр. Хезмәткәр үз теләген белдереп,профсоюзга керү турында гариза яза. Мәгариф бүлегенең мәгариф оешмаларының үзәкләштерелгән бухгалтериясе тарафыннан ай саен членлык взнослары Әтнә территориаль профсоюз оешмасы счетына күчерелеп бара.

Профсоюз комитеты үзенең утырышында башлангыч профсоюз оешмасының еллык сметасын раслый. Сметада мәдәни-массакүләм, спорт-сәламәтләндерү чараларын үткәрү, хезмәтне саклауга, информацион эшчәнлекне оештыруга юнәлдерелгән чыгымнарга, профсоюз членнарының юбилейларын билгеләп үтү, аларның шәхси гаризалары буенча матди ярдәм күрсәтү өчен акчалар каралган. Аерым чарага акча тоту мәсьәләсе профком утырышында каралып үтә, утырыш карары чыгарыла. Карарга нигезләнеп, территориаль профсоюз оешмасына заявка бирелә. Утырыш карарына өстәп тотылган акчаларның чыгымнарын дәлилләүче финанс документлар теркәлә. Профсоюз членнарына аларның шәхси гаризалары нигезендә матди ярдәм күрсәтү каралган. Матди ярдәм профсоюз членнарының сәламәтлекләрен ныгыту максатыннан ,озак вакыт эшкә сәләтсезлек, инвалидлык, бәла-казаларга юлыгу очракларында бирелә.

## 7. Профсоюз комитетының эшен яхшырту буенча тәкъдимнәр

Бүгенге заман кайсы өлкәләрдә генә булмасын , бер урында таптанып торырга, элеккеге уңышлар белән генә яшәргә ярамаганлыкны раслый.Безне чолгап алган информация искиткеч зур тизлек белән яңара бара,мәгариф өлкәсендә дә яңадан яңа технологияләр барлыкка килә. Бу үз чиратында укыту-тәрбия процессындагы кадрлардан үзләренең белемнәрен, компетенцияләрен даими күтәрүне таләп итә.

Димәк, яңа шартларда яшәргә һәм эшләргә өйрәнгән хезмәткәрләрнең профессиональ союзларга карата таләпләре дә үзгәрә. Шуңа күрә дә безгә профсоюзлар, профкомнар эшчәнлеген яңарту, эш формаларын камилләштерү, даими эзләнү, коллективның атмосферасын тою, профсоюз членнарының фикерләрен тыңлау, теләкләрен өйрәнү эшенә басым ясарга кирәк булачак.

Мәгариф системасы Профсоюзларының төп максаты – илебездә барган социаль-икътисадый үзгәрешләр чорында профсоюз членнарының хезмәт хокукларын, социаль гарантияләрен яклау, укытучы һөнәренең абруен күтәрү бурычы тора. Бүгенге көндә профсоюз комитетының башкарылган эшләр белән бер рәттән алда эшләнәсе күп эшләре бар:

- киләчәктә хезмәткәрләрнең профсоюз сафына керүне мотивацияләүче уңай факторларны актив пропагандалау;
-оештыру эшләренә яшь профсоюз членнарын җәлеп итү;
- мәдәни-массакүләм һәм спорт-сәламәтләндерү эшен оештыруда яңа кызыклы проектларны тормышка ашыруны максат итеп кую;
-яшь укытучылар белән эшләүгә даими игътибар бирү, остазлык хәрәкәтен киңрәк җәелдерү;
-профсоюз членнарының фикерләрен тыңлау, теләкләрен өйрәнү максатыннан “түгәрәк өстәлләр” форматында психологик тренинглар уздыру;
-2024 нче елның Гаилә елы булуын исәпкә алып, мәдәни-массакүләм һәм спорт чараларын оештыруга профсоюз членнарының актив катнашуын тәэмин итү.

Профсоюз комитетына һәм аның комиссияләренә билгеләнгән проблемалар өстендә эшләргә, үзләрен мәктәп тормышында башлангыч профсоюз оешманың ролен тагын да активрак белдерергә тырышырга туры киләчәк. Бу беренче чиратта, оешмабыз хезмәткәрләренең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау, законлылыкны саклау,һәр профсоюз членының шәхси хезмәт нәтиҗәләрен һәм коллективның уртак эше өчен җаваплылыкны арттыруга кайтып кала.

Отчет чорында профсоюз комитетының барлык членнарына да йөкләнгән эшне зур җавапчылык белән башкарганнары өчен рәхмәт белдерәсем килә, югыйсә, бу вазыйфалар алар тарафыннан бушка башкарыла. Шул ук вакытта коллективыбызда “уртак эшләнгән эш барыбыз өчен дә кирәкле эш,”- дип янып йөрүче хезмәткәрләребез булуы шатландыра.Бу аларның гражданлык позициясе.

Шулай ук социаль партнерларыбызга да үзара аңлашып, уртак фикергә килеп эшләүләренә рәхмәт сүзләрен әйтергә телим. Без оешмабызның хезмәткәрләре өчен уңай эш шартлары булдыру, укыту-тәрбия процессының нәтиҗәлеген арттыру өчен уртак эш башкарабыз .

Чыгышымның ахырда шуны әйтеп үтәргә телим: киләчәктә профсоюз оешмасы коллективта дустанә климат тудыручы, социаль партнерлык статусын аклаучы, оешмабызның һәр члены өчен иҗади һәм һөнәри планнарын тормышка ашыруда мөмкинлекләр тудыручы оешма булып калсын иде.